# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлегенең Түбән Юшады торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**18.11.2022ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принципиплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча 18.11.2022 елда үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде: «2023 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге Түбән Юшады торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 1300 сум күләмендә үзсалым кертергә ризамыһәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү:

- Түбән Юшады торак пунктында авылга керү авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

- Түбән Юшады торак пунктында урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам яктырту өчен фотореле сатып алу һәм урнаштыру, энергияне саклый торган яктырткычларны һәм урам яктырту лампаларын алыштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 45 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 25 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
халык җыенында катнашкан 25 кеше «РИЗА»позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде 0 җыенда катнашучылар.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар чыгарды:

1. Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлегенең Түбән Юшады торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылды.

2. 2023 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге Түбән Юшады торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 1300 сум күләмендә үзара салым кертүгә карар кабул ителгән дип расларга,- алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Түбән Юшады торак пунктында авылга керү авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак

таш сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

- Түбән Юшады торак пунктында урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам яктырту өчен фотореле сатып алу һәм урнаштыру, энергияне саклый торган яктырткычларны һәм урам яктырту лампаларын алыштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Юшады авыл җирлегенең мәгълүмати стендына урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (http:// menselinsk.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:/pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 10 көн эчендә нәтиҗәләрне игълан итү.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Юшады авыл җирлеге башлыгы ______________ И.Р.Ханов
(имза)